# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Урманче поселогы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

5 декабрь 2020 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законының 35 статьясы нигезендә, «2021 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Урманче поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Урманчы поселогында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау (су башняларын тоту)

«ӘЙЕ» «ЮК»

дигән сорау буенча 2020 елның 5 декабрендә 11 сәгать 30 минутта узган гражданнар җиены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 202 (ике йөз ике) катнашучы кертелгән, 107 кеше тавыш бирүдә катнашкан, бу 52,9% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә билгеләнде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 101 (йөздә бере) «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде; «ЮК» позициясе өчен 6 (алты) җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Урманче поселогында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга.

2. 2021 елда үзара салым акчасын Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Урманче поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Урманчы поселогында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау (су башняларын тоту).

4. Әлеге карарны мәгълүмәт стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмәт рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырап чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.З.Газизов